Яр Чаллы шәһәре Үзәкләштерелгән
китапханәләр системасы директоры
_____________ В.М.Гайнуллина
"17" 01 2018 ел

## "Әкияттә хикмәт бар"

шәһәркүләм инсценировкалар видеоконкурсы

**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

Яр Чаллы китапханәләр системасының 12нче санлы татар китапханәсе татар теле, татар әдәбиятының дәрәҗәсен арттыру максатыннан "Әкияттә хикмәт бар" шәһәркүләм инсценировкалар видеоконкурсы игълан итә.

### 1.Конкурсның максаты:

1.1.Балаларда сәнгать аша кешелеклелек, шәфкатьлелек, ярдәмчеллек, изгелек сыйфатларын, сәхнә культурасын тәрбияләү.
1.2.Татар әдәбиятына карата мәхәббәт тәрбияләү, татар теленең дәрәҗәсен арттыру.

### 2.Конкурсның шартлары:

2.1.Конкурс 6-13 яшьлек түбәндәге балалар төркемнәре арасында үткәрелә:
- мәктәпкәчә яшьтәге балалар;
- кече яшьтәге мәктәп балалары;
- урта яшьтәге мәктәп балалары.

2.2.Конкурста катнашу өчен теркәлү карточкасы тутырырга кирәк (Кушымта №1).
2.3.5-8 баладан торган төркем, таяклы яки перчаткалы йомшак курчаклар кулланып, татар халык әкиятен яки татар язучылары әкиятен татар телендә сәхнәләштерә.
2.4.Тамашаның дәвамлыгы мәктәпкәчә яшьтәге балалар төркеме өчен 10-15 минут, кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары төркеме өчен 15-20 минут.
2.5.Чыгышлар видеога төшерелеп, видеоязма китапханәнең электрон адресына җибәрелә: cbs_filial12@mail.ru. Видеоязманың форматы – wmv, mp4. Видеоязманы китапханәгә китерергә дә мөмкин: Яңа шәһәр, 14/01. Белешмәләр өчен телефон: 35-33-86.
2.6.Бәйгедә катнашу бәясе - төркем өчен 100 сум (Кушымта №2).
2.7.Теркәлү карточкасы, түләү квитанциясенең копиясе һәм видеоролик 12нче апрельгә кадәр кабул ителә. Эшләр билгеләнгән вакытка килеп җитмәсә, бәйгедә катнашмыйлар.

### 3. Конкурсны бәяләү:

3.1.Бәйгедә катнашучыларның татарча сәнгатьле итеп сөйләү һәм уйнау осталыклары бәяләнә.
3.2.Чыгышның музыкаль бизәлеше, декорацияләр һәм эшкә иҗади якын килү хуплана (өстәмә балл).
3.3. Башка милләт кешеләренең видеоязмалары (татар телендә) аерым номинациядә бәяләнә.
3.4. Җиңүчеләр Яр Чаллы китапханәләр системасының Дипломнары белән бүләкләнәләр.
3.5. Бәйгедә катнашучыларга электрон вариантта сертификатлар тапшырылачак.

3.6. Бәйгедә җиңүчеләр исемлеге Яр Чаллы китапханәләр системасының сайтында, 12нче санлы татар китапханәсенең «В контакте» социаль челтәрендәге битендә урнаштырылачак.
3.7.Җиңүчеләрнең видеоязмалары шәһәр китапханәләре үткәргән чараларда кулланылачак.

**4.Бәйгене йомгаклау**

Бәйгене йомгаклау 19нчы апрель көнне 14.00 сәгатьтә Яр Чаллы китапханәләр системасының 12нче санлы татар китапханәсендә узачак: Яңа шәһәр, 14/01 йорты.
Жюри составында Яр Чаллы шәһәре Үзәкләштерелгән китапханәләр системасының методистлары, Яр Чаллы шәһәре Үзәкләштерелгән китапханәләр системасының 12нче санлы татар китапханәсе хезмәткәрләре, "Заман" яшьләр үзәге белгечләре булачак.

**Кушымта №1.**

**ТЕРКӘЛҮ КАРТОЧКАСЫ**

1.Төркем житәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме

______________________________________________

______________________________________________

2.Катнашучыларның яше______________________________

3.Катнашучыларның саны ________

4.Телефон_____________________________, E-mail__________________________

5.Төркем житәкчесенең эш урыны

______________________________________________

6.Әсәрнең авторы, исеме_____________________________

**Кушымта №2.**

**РЕКВИЗИТЫ ДЛЯ ПЕРЕЧИСЛЕНИЯ ОРГАНИЗАЦИОННОГО ВЗНОСА**
МБУ «Централизованная библиотечная система»
ИНН/КПП 1650105517/ 165001001
Расч. счет 40701810692053000045
Корр.счет 30101810600000000805
БИК 049205001
Банк Отделение - НБ Республика Татарстан
Лицевой счет ЛБВ 30800866-ЦБС
Назначение платежа **На конкурс "Әкияттә хикмәт бар"**
**Библиотека-филиал №12**
**ФИО руководителя группы**__________________________